ФГОС

Школьный учебник
«Татарский язык»

КҮҢЕЛЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ

Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ



## 3 класс

БЕРЕНЧЕ КИСӘК

Татармультфильм

ИЗДАТЕЛЬСТВО
«Татармультфильм»




Мәктәп

Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина

# ТАТАР ТЕЛЕ

## ӨЧЕНЧЕ СЫЙНЫФ

БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ
ОЕШМАЛАРЫ ӨЧЕН ДӘРЕСЛЕК
(РУС ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЛӘРЕНДӘ)

ДӘРЕСЛЕК Е.И.ПАССОВНЫҢ
КОММУНИКАТИВ ТЕХНОЛОГИЯ КОНЦЕПЦИЯСЕНӘ НИГЕЗЛӘНӘ

Ике кисәктә

1 НЧЕ КИСӘК

КАЗАН
«ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ» НӘШРИЯТЫ
2013

Р.З.Хайдарова, Г.М.Ахметзянова, Л.А.Гиниятуллина

# ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК

## ТРЕТИЙ КЛАСС

УЧЕБНИК ДЛЯ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ
НАЧАЛЬНОГО ОБЩЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
(НА РУССКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ)

НА ОСНОВЕ КОНЦЕПЦИИ КОММУНИКАТИВНОЙ ТЕХНОЛОГИИ
Е.И.ПАССОВА

В двух частях

ЧАСТЬ 1

КАЗАНЬ
ИЗДАТЕЛЬСТВО «ТАТАРМУЛЬТФИЛЬМ»
2013

УДК 811.512.145(075)
ББК 81.632.3я722
Х85

## Условные обозначения:

 — начало урока

— запомни

— вспомни

 — обрати внимание

**Хайдарова, Р.З. и др.**

Х85 Татарский язык: учебник для образовательных организаций начального общего образования, в 2-х частях (на русском и татарском языках). / Р.З. Хайдарова, Г.М. Ахметзянова, Л.А. Гиниятуллина. — Казань : Татармультфильм, 2013. — 112 с. : ил. — (Татар теле). — ISBN 978-5-9903561-4-6.

**ISBN 978-5-9903561-4-6**

**УДК 811.512.145(075)**
**ББК 81.632.3я722**

© Издательство «Татармультфильм», 2013
© Художественное оформление
Издательство «Татармультфильм», 2013
Все права защищены






ИЗДАТЕЛЬСТВО
«Татармультфильм»

# БЕЛЕМ БӘЙРӘМЕ

## 1–3 нче дәресләр

**1.** Внимательно рассмотри рисунок. Кого ты видишь? Как назовёшь рисунок?




**2. Исеңдә калдыр! Запомни!**



**Белéм бәйрәмé** – Праздник знаний
**укý** – учёба
**башланá** – начинается
**котлы́йбыз** – поздравляем
**уңышлáр** – успехи

**3. Исеңә төшер! Вспомни!**

**Синé котлы́йм!** – Поздравляю тебя!
**Сезнé котлы́йм!** – Поздравляю вас!
**Сезнé котлы́йбыз!** – Поздравляем вас!

**4.** Прочитай текст. Научись поздравлять учителей.

Бүге́н зур бәйрә́м – 1 нче сентя́брь. Мәктәптә́ укула́р башлана́. Без мәктәпкә́ бара́быз. Мәктәптә́ безне́ укытучыла́р көтә́. Без аларга́ чәчәклә́р бирә́без.

Кадерле́ укытучыла́р! Сезне́ Беле́м бәйрәме́ белән котлы́йбыз! Сезгә́ уңышла́р тели́без!

**5.** **Исеңә төшер! Вспомни!**

**Кем?** (кто?) – син, сез
**Ке́мне?** (кого?) – сине́, сезне́
**Ке́мгә?** (кому?) – сиңа́, сезгә́

**6.** Найди подходящие рисунки к предложениям: **Сине́ котлы́йм! Сезне́ котлы́йм!** Чем они отличаются?





**7.** Какие комплименты говорят девочки друг другу?



– Син бүге́н би́к мату́р!
– … .
– Сине́ң көлмәге́ң мату́р!
– … .



**8.** Поздравь друга с праздником 1 сентября. Нарисуй своё поздравление и подпиши.

**9. Исенңә төшер! Вспомни!**

| **Ка́я?** – Куда? | **Ка́йда?** – Где? | **Ка́йдан?** – Откуда? |
|---|---|---|
| **-га/-гә**<br>**-ка/-кә** | **-да/-дә**<br>**-та/-тә** | **-дан/-дән**<br>**-тан/-тән**<br>**-нан/-нән** |

**10.** Марат нишли?




**11.** Используя рисунок упражнения №1, составь два диалога и поговори с другом.

## 4–6 нчы дәресләр

**1. Исенңә төшер! Вспомни!**

**слово + -мы/-ме = ?**
**Бу кита́пмы?** – Это книга?

**2.** Шурале забыл названия учебных принадлежностей. Помоги ему вспомнить.



**3.** Шурале хочет уточнить названия учебных принадлежностей. Какие вопросы он задаст? Ответь ему, используя слова **әйе́**, **юк**.

**4.** **Исеңә төшер!**

| | | | |
|---|---|---|---|
| **миңа́** | — мне | **кирә́к** | — надо |
| **сиңа́** | — тебе | **кирә́к түгел** | — не надо |
| **аңа́** | — ему (ей) | **кирә́кми** | — не надо |

**5.** К каким рисункам подходят эти предложения?




1) Сиңа́ кита́п кирә́кме?
2) Миңа́ кита́п кирә́к.
3) Бу – миние́м китабы́м.

**6.** Продолжи по образцу.

Образец: Бу дәфтә́р ке́мгә? – Бу дәфтә́р А́няга. – Бу дәфтә́р аңа́.

1) Бу кита́п Пе́тяга. 2) Бу пена́л Са́шага. 3) Бу лине́йка Ләйсәнгә́. 4) Бу су́мка Алсуга́.

**7.** Используя содержание упражнения №5 и объясняя жестами, поговорите друг с другом.

**8.** Используя рисунки упражнения №2:

– попроси себе учебные принадлежности;
– спроси у друга, нужна ли ему тетрадь (книга, ...);
– предложи другу эти учебные принадлежности.

**9.** **Исеңә төшер!**

**Ни́чә?** – Сколько?

| | |
|---|---|
| **1 – бер** | **6 – алты́** |
| **2 – ике́** | **7 – җиде́** |
| **3 – өч** | **8 – сиге́з** |
| **4 – дүрт** | **9 – тугы́з** |
| **5 – биш** | **10 – ун** |

**10.** Продолжи диалог. Поговори с соседом по парте. Составь аналогичный диалог.



– Сәла́м, Са́ша!
– Сәла́м, Була́т!
– Сиңа́ дәфтә́р кирә́кме?
– Әйе́, кирә́к.
– Ни́чә дәфтә́р кирә́к?
– … .
– Ә кита́п кирә́кме?
– … .
– Ни́чә кита́п кирә́к?
– … .



## 7–9 нчы дәресләр

**1.** Рәсемгә кара һәм әйт: нинди карандашлар бар, алар ничә?



**2. Исеңдә калдыр!**



**озы́н** – длинный
**кыска́** – короткий

**3.** 1 нче күнегүдәге рәсемгә кара һәм әйт: нинди карандашлар озын, нинди карандашлар кыска?

**4.** Используя рисунок упражнения №1:

– спроси у друга, нужны ли ему карандаши; какие карандаши ему нужны;

– предложи ему эти карандаши.

**5. Исеңдә калдыр!**





**Шакмаклы́ дәфтә́р.**



**Сызыклы́ дәфтә́р.**

**6.** Как скажешь о том, что:

– у тебя есть тетрадь в линейку;

– у тебя нет тетради в клетку;

– тебе не нужна тетрадь в линейку, а нужна в клетку?

**7. Исеңә төшер!**

**-лар/-ләр, -нар/-нәр** –

аффиксы множественного числа:

китá п – кита**плá р**

дәфтә́р – дәфтәр**лә́р**

урмá н – урман**нá р**

көн – көн**нә́р**

В татарском языке имя существительное при числительных употребляется в единственном числе: **өч алмá , биш дәфтә́р, дүрт карандá ш.**

**8.** Саннар нинди төстә?




**9.** Дополни диалог. Поговори с другом.

– Сиңá кызы́л карандáш кирǝ́кме?
– ... .
– Сиңá ни́нди карандáш кирǝ́к?
– ... .
– Сиңá ни́чә дәфтǝ́р кирǝ́к?
– ... .

**10.** **Исеңдә калдыр!**

| | |
|---|---|
| **алáм** – беру | **салáм** – кладу |

**11.** Рәсемнәргә кара, җөмләләр төзе.



**12.** Используя рисунки упражнения №11, составь диалог. Поговори с соседом по парте.

# 10–12 нче дəреслəр

**1. Исеңдə калдыр!**



**Исе́м** – имя существительное

Имена существительные обозначают предметы и отвечают на вопросы **кем?** (кто?) и **нə́рсə?** (что?).

В отличие от русского языка на вопрос **кем?** отвечают только имена существительные, обозначающие людей. Н а п р и м е р: **эни́, эти́, кыз, мала́й, укучы́.**

Все остальные существительные отвечают на вопрос **нə́рсə?**

**2.** Назови эти предметы. Слова, отвечающие на вопрос **кем?**, напиши в первый столбик, на вопрос **нəрсə?** – во второй.



| Кем? | Нə́рсə? |
|---|---|
| … | … |

3. Прочитай диалог и разыграй его с соседом по парте.

– Исә́нме, Ра́дик!
– Исә́нме, Арту́р!
– Хәллә́р ни́чек?
– Рәхмә́т, яхшы́. Бүге́н бәйрә́м, мин би́к шат.
– Ми́н дә би́к шат. Сине́ бәйрә́м белән котлы́йм!
– Ми́н дә сине́ котлы́йм! Уңышла́р тели́м!

4. Сүзләрне дөрес укы.

Котлыйм [қо̆тлы́йм], яхшы [йаᵒхшы́], шат [шаᵒт], килешә [килэ̆шә́], уңышлар [уңы́шла́р], дәрес [дәрэ̆́с], ашамлык [аᵒшамлы́қ], кәеф [кәйэ̆́ф].

5. **Исеңдә калдыр!**

мой (моя) – **мине́м** китаб**ы́м**, көндәлег**е́м**
твой (твоя) – **сине́ң** китаб**ы́ң**, көндәлег**е́ң**
его (её) – **аны́ң** китаб**ы́**, көндәлег**е́**

Согласные звуки **[к]**, **[қ]**, **[п]** в конце слов при добавлении аффиксов **-ым/-ем**, **-ың/-ең**, **-ы/-е** чередуются со своими звонкими парами **[г]**, **[ғ]**ғ и **[б]**:

көндәлé**к** – көндәле**г**е́м   күлмә́**к** – күлмә**г**е́м
урынды́**к** – урынды**г**ы́м   ту**п** – ту**б**ы́м

6. Синең нинди уку-язу әсбапларың (учебные принадлежности) бар? Аларны дәфтәреңә яз.

**7.** Спроси у соседа по парте:

а) есть ли у него тетрадь в клетку (в линейку), цветные карандаши;
б) где находится его сумка.

**8.** Спиши, вставляя вместо рисунков нужные слова.

1) Минéм яңá  бар. 2) Мин сýмкага  салды́м. 3) Йра миңá  бирдé.

**9.** Составь диалог по содержанию упражнения №7.

**10.** Перескажите содержание упражнения №7 друг другу.

**11.** Бәйрәмдә кешеләр бер-берсенә (друг другу) комплиментлар әйтәләр. Бу комплиментларның сиңа кайсысы (который) ошый?



– Син бүгéн би́к матýр!
– Синéң көлмәгéң матýр!
– Синéң сýмкаң яңá!
– Костюмы́ң сиңá килешә́ (подходит)!
– Сиңá бу костю́м би́к килешә́!

**12.** Укытучыгызга, бер-берегезгә (друг другу) комплиментлар әйтегез.

## 13–15 нче дәресләр

**1.** **Исеңдә калдыр!**

**Фигы́ль** – глагол

Глаголы обозначают действие предметов и отвечают на вопросы **ни́шли?** (что делает?), **ни́шләде?** (что сделал?).

Чтобы правильно употребить глагол в речи, ты должен уметь определять его основу, начальную форму. Начальная форма глагола совпадает с формой глагола 2 лица единственного числа, которая выражает повеление, совет, приказ:

| | |
|---|---|
| **бар** – иди | **кил** – приходи |
| **әйт** – скажи | **яз** – пиши |
| **ач** – открой | **сө́йлә** – расскажи |

**2.** Сүзләрне дөрес укы. Тәрҗемә ит.

Ач [а°ч], тор [тŏр], куй [ķуй], ят [йа°т], йөгер [йө́гөр], укы [у́ķы], җырла [җы́рла], тыңла [ты́ңла].

**3.** Представь, что ты тренер. Скомандуй: «беги!», «сядь!», «ляг!», «встань!».

**4.** Выпиши глаголы, выражающие действия, которые происходят сейчас. Составь 5 предложений.

Укы́й, язды́, килде́, яза́, эшли́, эшләде́, сөйли́, бирә́, ала́, салды́, килә́, китте́.

**5. Исеңдә калдыр!**

**Хәзергé замáн** — настоящее время

Говорить о действиях, которые происходят сейчас, помогают аффиксы **-а/-ә; -ый/-и**, которые присоединяются к начальной форме глагола:

бар+**á** – бара (идёт)
кил+**ә́** – килә (приходит)
кайт+**á** – кайта (возвращается)
кит+**ә́** – китә (уходит)

**Үткә́н замáн** — прошедшее время

Говорить о действиях, которые уже произошли, помогают аффиксы **-ды/-де, -ты/-те**, которые присоединяются к начальной форме глагола:

бар+**ды́** – барды (сходил)
кил+**дé** – килде (пришёл)
кайт+**ты́** – кайтты (вернулся)
кит+**тé** – китте (ушёл)

**6. Исеңдә калдыр!**

| **Хәзерге заман** | **Үткән заман** |
|---|---|
| Мин бар+á+м, кил+ә́+м.<br>Син бар+á+сың, кил+ә́+сең.<br>Ул бар+á, кил+ә́. | Мин бар+ды́+м, кил+дé+м.<br>Син бар+ды́+ң, кил+дé+ң.<br>Ул бар+ды́, кил+дé. |

**7.** Дополни диалог. Разыграй его с соседом по парте.

– ... ?
– Мин стадионга́ барды́м.
– Стадионда́ ни́шләдең?
– ... .

**8.** Составь схожие диалоги со словами **мәктәп, цирк.**

**9.** Как бы ты спросил, чтобы получились такие ответы? Поговори с соседом по парте.

– ... ?
– Бүге́н 5 нче сентя́брь. Сишә́мбе.
– ... ?
– Бүге́н Наилә́ дежу́р.
– ... ?
– Бүге́н И́ра юк.

**10.** Как скажешь о том, что:

– ты сегодня дежурный в классе;
– ты учишься в третьем классе;
– в классе 25 учеников: 10 мальчиков, 15 девочек;
– классный руководитель Алсу Галиевна?

**11.** Выполни письменно упражнение №10.

# 16–18 нче дәресләр

**1.** **Исеңдә калдыр!**



**билгé** – отметка
**ни́нди?** – какой? какая? какие?
**ни́чәле?** – сколько? какую отметку?

**«5»–«биш»лé** **«3»–«өч»лé**
**«4»–«дүрт»лé** **«2»–«ике»лé**

**. – нокта́** **, – өтéр** **? – сора́у**

**2.** Разыграйте диалоги.

1) – Без бүгéн дикта́нт язды́к.
– Ни́нди билгé алды́ң?
– «Дүрт»лé.

2) – Син бүгéн билгé алды́ңмы?
– Әйé. Матема́тикадан (по математике).
– Ни́чәле?
– «Дүрт»лé.

3) – Син «ике»лé алды́ңмы?
– Юк.
– Ни́чәле алды́ң?
– «Биш»лé.
– Яхшы́, би́к яхшы́!

**3.** Бу сүзләрне дөрес укы.

Кечкенә [кә̆чкә̆нә́], укучы [уқучы́], хата [ха°та́], хатасыз [ха°тасы́з], тикшердек [тикшә̆рдә̆́к].

**4.** Тәрҗемә ит. Җөмләләр уйла.

хата́ – ...
хатасы́з – ...
хатасы́ бар – ...
хатасы́ юк – ...
хата́ белән – ...

**5.** Сүзләрнең антонимнарын тап.

кечкенә́ – ...
чиста́ – ...
җиңе́л – ...
мату́р – ...

**6.** **Исеңдә калдыр!**



| | |
|---|---|
| Без бар+ды́+к. | Без кил+де́+к. |
| Сез бар+ды́+гыз. | Сез кил+де́+гез. |
| Ала́р бар+ды+ла́р. | Ала́р кил+де+лә́р. |

**7.** Текстны укы, исем бир.

Без бүге́н дәрестә́ кечкенә́ дикта́нт язды́к. Дикта́нт җиңе́л булды́. Без диктантны́ дәрестә́ тикшерде́к. 4 укучы́ – «биш»ле́, 6 укучы́ – «дүрт»ле́, 3 укучы́ «өч»ле́ алды́. Мине́м дусты́м Оле́г чиста́, хатасы́з язды́. Ул «биш»ле́ алды́. Ә мине́м 2 хата́м ба́р иде. Мин «дүрт»ле́ алды́м.



**8.** Расположи предложения по содержанию текста.

1) Диктáнт җиңéл иде. 2) Минéм дустым́ Олéг чистá, хатасы́з язды́. 3) Без бүгéн дәрестә́ кечкенә́ диктáнт яздыќ. 4) Мин «дүрт»лé алдым́.

**9.** Спиши предложения, вставляя пропущенные буквы.

1) Мин диктáнт язды... . 2) Без диктáнт язды... . 3) Мин «биш»лé алды... . 4) Без «биш»лé алды... . 5) Мин чистá, хатасы́з язды... . 6) Без чистá язды... .

**10.** Җөмләләрне үрнәк буенча (по образцу) киңәйтеп (распространив) яз.

Ү р н ә к: Без яздыќ. Без диктáнт яздыќ.
Без бүгéн дәрестә́ диктáнт яздыќ.

Җ ө м л ә л ә р: Без тикшердéк. Олéг язды́.

**11.** Расскажите друг другу содержание упражнения №7.

## 19–20 нче дәресләр

**1.** **Исеңә төшер!**

Глаголы с аффиксом **-мый/-ми** указывают на то, что действие не происходит, и отвечают на вопрос **нишлә́ми?** (что не делает?):

укы́й – укы́ + **мый** — язá – я́з + **мый**

килә́ – ки́л + **ми** — барá – бáр + **мый**

**2.** Как ты скажешь, если Костя не выполняет эти действия? Составь 4 предложения.

Кита́п укы́й, күнегу́ яза́, хата́ ясы́й, «3»ле́ ала́, «5»ле́ куя́, җөмлә́ яза́, мәктәпкә́ бара́, стадионда́ уйны́й, котлы́й, чәчә́к бүлә́к итә.

**3.** Эти предложения помогут тебе оценить чтение товарища. Запомни их!



дөре́с укы́й – дөре́с укы́мый
мату́р укы́й – мату́р укы́мый
яхшы́ укы́й – яхшы́ укы́мый
нача́р укы́й – нача́р укы́мый

**4.** Диалогларны сөйләшегез.



а) – О́ля дөре́с укы́ймы?
– Әйе́, О́ля дөре́с укы́й.
– Пе́тя нача́р укы́ймы?
– Юк, Пе́тя нача́р укы́мый, яхшы́ укы́й.




ә) – Ната́ша хата́ ясы́ймы?
– Ната́ша хата́ яса́мый.
– Ко́ля мату́р сөйли́ме?
– Юк, Ко́ля мату́р сөйлә́ми.

**5.** Объявляется конкурс на лучшего чтеца текста «Без диктант яздык!». Читай эти слова внимательно.

Бүген [бүгә̆́н], кечкенә [кә̆чкә̆нә́], яздык [йа°зды́к], җиңел [җиңә̆́л], укучы [уқучы́], тикшердек [тикшә̆рдә̆́к], дустым [дусты́м], хатасыз [ха°тасы́з], хатам [ха°та́м].

**6. Исеңә төшер!**

**Ни́чә?** – Сколько? **Ни́чек?** – Как?
**Ка́йчан?** – Когда?

**7.** Подумай, какие вопросы можно поставить к этим предложениям.

1) Дикта́нт җиңе́л иде. 2) Без диктантны́ дәрестә́ тикшерде́к. 3) Дусты́м Оле́г хатасы́з, чиста́ язды́. 4) Мине́м 2 хата́м ба́р иде.

**8.** Сообщи другу о том, что:

– сегодня у вас пять уроков;
– на втором уроке была контрольная работа;
– во вторник писали диктант;
– ты не делаешь ошибок.

**9.** Спроси у друга:

– писали ли они сегодня диктант;
– какие оценки он получил за диктант;
– кто писал чисто и без ошибок.

**10. Исеңдә калдыр!**

**чө́нки** – потому что
**лә́кин** – но
**ба́р иде** – было

Оле́г «биш»ле́ алды́, **чө́нки** хатасы́з язды́. – Олег получил «пятёрку», **потому что** написал без ошибок.

О́ля чиста́ язды́, **лә́кин** бер хатасы́ ба́р иде. – Оля написала чисто, **но** была одна ошибка.

**11.** Вставь пропущенные реплики в диалог. Поговори с соседом по парте.

– Син диктантта́н (по диктанту) ни́чәле алды́ң?
– ... .
– Ни́чә хата́ң ба́р иде?
– ... . Ә си́н ни́нди билгé алды́ң?
– ... , чө́нки хата́м ба́р иде.
– Ни́чә хата́ң ба́р иде?
– ... .



**12.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Са́ша «4»лé алды́, чө́нки ... .
2) Ма́ша «5»лé алды́, лә́кин ... .

## 21–22 нче дәресләр

**1.** Сүзләрне дөрес укы. Тәрҗемәсен **истә калдыр!**



**сорау бирә** [сŏра́°w бирә́] – задаёт вопрос
**җавап бирә** [җа°wа́п бирә́] – отвечает
**хата төзәтә** [ха°та́ төзәтә́] – исправляет ошибку
**мәсьәлә чишә** [мәсˁәлә́ чишә́] – решает задачу

**2.** Бу эшләрне кем эшли? Үрнәк буенча әйт.

Күнегу́ эшли́, сора́у бирә́, җава́п бирә́, күрсәтә́, укы́й, сөйли́, тыңлы́й, хата́ төзәтә́, рәсе́м ясы́й, аңлата́.

Үрнәк:

Укытучы́ сора́у бирә́. Укучы́ күнегу́ эшли́.
... ...

**3. Исеңә төшер!**

В татарских словах гласные бывают или только мягкие, или только твёрдые. Например: **ки-лә́-ләр, ки-тә́-ләр, ба-ра́-лар, кай-та́-лар.**

Исключение составляют заимствованные слова. Например: **ки-та́п, пе-на́л, ке́п-ка.**

**4.** Раздели каждое слово на слоги. Укажи твёрдые и мягкие гласные.

Сора́у бирә́ләр, күнегу́ эшли́, хатала́р төзәтә́, җава́п бирә́ләр, хикәя́ укы́йбыз, миса́л чишә́сез, аңлата́лар.

**5. Исеңдә калдыр!**



**үзе́м** – сам(а)
Мин **үзе́м** эшли́м. – Я сам(а) делаю.
Син **үзе́ң** эшли́сең. – Ты сам(а) делаешь.
Ул **үзе́** эшли́. – Он (она) сам(а) делает.

**6.** Сравни данные парами слова и словосочетания. Чем они отличаются друг от друга?

хикәя́ укы́й — җава́п бирә́
хикәя́ укы́йлар — җава́п бирә́ләр

сора́у бирә́ — аңлата́
сора́у бирә́ләр — аңлата́лар

миса́л чишә́ — билге́ ала́
миса́л чишә́ләр — билге́ ала́лар

**7.** Как скажешь, если действия упражнения №6 выполнил ты?

**8.** Спроси у друга, сам ли он:

– задал вопрос;
– ответил;
– решил пример;
– сделал упражнение.




**9.** Сүзләрне дөрес укы.

Иптәше [иптәшэ̆́], өченче [өчөнчө́], укыды [уқы̆ды̆́], чиште [чиштэ̆́], хикәя [хикәйә́], Равил [ра$^{o}$wи́л], аңлады [а$^{o}$ңлады̆́], аңлата [а$^{o}$ңлата́], күчерә [күчэ̆рә́], ярдәм [йәрдә́м], дөрес [дөрө́с].

**10.** Хикәяне укы. Зөфәр нинди хата ясады?

### Чын иптә́ш



Закирны́ң ике́ иптәше́ бар: Рави́л һәм Зөфә́р. Ала́р өченче́ сыйныфта́ укы́йлар.

Балала́р өйдә́ хикәя́ укыдыла́р һәм мисалла́р чиштелә́р.

Заки́р хикәяне́ укыды́, лә́кин мисалларны́ чи́шмәде. Ул икенче́ көнне́ мәктәпкә́ килде́ һәм иптәшләреннә́н ярдә́м сорады́. Зөфә́р үз дәфтәре́н аңа́ бирде́ дә:

– Мә, кү́чер, мин мисалны́ дөре́с эшләде́м, – диде́.

Ә Рави́л:

– Юк, Заки́р, күче́рмә. Мин сиңа́ хә́зер үзе́м аңлата́м, син үзе́ң э́шлә, – диде́.

Мәрья́м Галлә́мова

**иптә́ш** (дус) – друг **ярдә́м сорады́** – попросил помощи
**аңлата́м** – объясню **чиште́** – решил

**11.** Хикәяне сәнгатьле (выразительно) укырга өйрән.

## 23–25 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



**Нишлә́мәде?** – Что не сделал?
Если действия не происходили, то говорят так:
я́з +**ма**+ды – **не** писал
чи́ш+**мә**+де – **не** решал
Мин я́з+ма+ды+м, чи́ш+мә+де+м.
Син я́з+ма+ды+ң, чи́ш+мә+де+ң.
Ул я́з+ма+ды, чи́ш+мә+де.

**2.** Төшеп калган репликаларны өстәп, диалогны укы.

– Син мисалны́ үзе́ң чиште́ңме?
– ... .
– ... ?
– Юк, мәсьәләне́ үзе́м чи́шмәдем.

**3.** Расположи предложения по содержанию текста.

1) Рави́л, Зөфә́р, Заки́р өченче́ сыйныфта́ укы́йлар. 2) Балала́р өйдә́ хикәя́ укыдыла́р һәм миса́л чиштелә́р. 3) Закирны́ң ике́ иптәше́ бар. 4) Заки́р икенче́ көнне́ мәктәпкә́ килде́ һәм иптәшләреннә́н ярдә́м сорады́.

**4.** Җөмләләрне киңәйтеп (распространив) яз.

1) Балала́р чиштелә́р. 2) Мин аңлата́м. 3) Заки́р чи́шмәде.

**5.** Ике раслауның кайсысы (который) дөрес? Дөрес раслауны дәфтәргә яз.

1) Укучыла́р өйдә́ мәсьәлә́ чиштелә́р.
   Укучыла́р өйдә́ миса́л чиштелә́р.
2) Заки́р хикәяне́ укыды́, мисалны́ чиште́.
   Заки́р хикәяне́ укыды́, мисалны́ чи́шмәде.
3) Зөфә́р Закирга́ дәфтәре́н бирде́.
   Зөфә́р Закирга́ мисалны́ аңлатты́.

**6.** Как скажешь, что:

– ты прочитал рассказ, но не решил задачу;
– ты решил задачу и сделал упражнения?

**7.** Спроси у друга:

– сколько примеров он сегодня решил;
– сам ли он решил задачу.

**8.** Диалогларны дустың белән сөйләш.

1) – Олéг, син мисалны́ чиштéңме?
– Әйé, ә син?
– Юк, мин чи́шмәдем. Миңá ярдә́м и́т әле.
– Яры́й, хәзер аңлатáм.

2) – Булáт, син мәсьәләнé чиштéңме?
– Әйé, үзéм чиштéм. Ә син?
– Юк, мин чи́шмәдем. Миңá ярдә́м и́т әле.
– Ә́йдә аңлатáм.
– Рәхмә́т.

3) – Айну́р, мин мәсьәләнé чи́шмәдем. Дәфтәреңнé би́р әле, күчерә́м.
– Юк, Кóстя, мин сиңá аңлатáм. Син үзéң чи́ш.
– Рәхмә́т.

**9.** Как попросишь помочь тебе? **Запомни!**



| | |
|---|---|
| **Миңá ярдә́м и́т әле**<br>**Миңá бу́лыш әле** | Помоги мне, пожалуйста. |

**10.** Допустим, что ты:

– не решил задачу;
– не решил пример;
– не сделал упражнение.

Скажи об этом. Попроси друга помочь тебе.

**11.** Как ты понимаешь выражения **чын ярдә́м** и **ялга́н ярдә́м?**

1) Закирга́ ка́йсы дусты́ чын ярдә́м күрсәтә́?
2) Син дустыңа́ ни́чек булыша́сың?

**12.** Шигырьне укы. Ошаса, ятла.

**Онытылга́н...**

Укучыла́р дәфтәрләре́н
Па́рталарга тезе́п салга́н.
– Дәфтәрләре́ң ка́йда, Мәсгу́ть?
– Онытылга́н... өйдә́ калга́н...
Иртәгесе́н бар балала́р
Кулларына́ кита́п алга́н.
– Китаплары́ң ка́йда, Мәсгу́ть?
– Онытылга́н... өйдә́ калга́н...
Башкаларны́ң «дүрт»ле́, «биш»ле́,
Мәсгу́ть та́гын «ике»ле́ алга́н.
– Ник башыңны́ эшлә́тмисең?
– Онытылга́н... өйдә́ калга́н...



Шәүкә́т Гали́ев

**13.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрән.

## 26–28 нче дәресләр

**1.** Раздели каждое слово на слоги. Укажи в них мягкие и твёрдые гласные.

Җыр, җырчы́, шигы́рь, кучерә́, хикәя́, миса́л, мәсьәлә́, кунегу́, җөмлә́, сора́у, җава́п, кита́п, чишә́, ошы́й.

**2. Исеңдә калдыр!**



**кита́п** – книга
**китапханә́** – библиотека
**китапханәче́** – библиотекарь

**3.** Рәсемнәргә кара һәм әйт: малай нишли?









**4. Исеңә төшер!**

**яныңда́** – около, рядом, возле, у

**5.** Предметлар кайда?







**6.** Диалогка репликалар өстә.

а) – Китапханә́ ка́йда?
– … .






ә) – Кибе́т ка́йда?
– … .






б) – Син ка́я бара́сың?
– … .
– Ә син ка́я бара́сың?
– … .




в) – Сиңа́ ни́нди китапла́р ошы́й?
– … .



**7.** Текстны укы.

**Китапханәдә́**

Оле́г китапханәгә́ еш бара́. Китапханә́ мәктә́п янында́ урнашка́н.

Оле́г китапханәгә́ Айда́р белән бара́. Китапханәдә́ кызыклы́ китапла́р күп. Олегка́ мавыгулы́ китапла́р ошы́й. Ул бу айда́ өч кита́п укыды́.

Китапханәче́ Алсу́ апа́ балаларны́ би́к ярата́. Ул аларга́ төрле́ китапла́р бирә́.

**мавыгулы́ китапла́р** – приключенческие книги

**8.** Бу җөмләләрнең кайсысы «Китапханәдә» текстына туры килә (подходит)?

1) Оле́г кита́п укы́й. 2) Оле́г китапханәгә́ еш ба́рмый. 3) Оле́г китапханәгә́ әнисе́ белән бара́. 4) Оле́г бу айда́ 3 кита́п укыды́. 5) Китапханә́ өй янында́ урнашка́н.

**9.** Сорауларга җавап бир.

1) Кем кита́п укы́й? 2) Китапханә́ ка́йда урнашка́н? 3) Олегка́ ни́нди китапла́р ошы́й? 4) Бу айда́ Оле́г ни́чә кита́п укыды́? 5) Ә син китапла́р укы́йсыңмы?

**10.** Күпнокталар урынына кирәкле сүзләрне яз. Текстны сөйләргә өйрән.

1) Мин ... укы́йм. 2) Мине́м ... күп. 3) Мин Айратка́ ... бирде́м. 4) Айратка́ ... би́к ошады́.

## 29–30 нчы дәресләр

**1. Исеңә төшер!**

| | | |
|---|---|---|
| Мин | а́л + мый + м, | эшлә́ + ми + м. |
| Син | а́л + мый + сың, | эшлә́ + ми + сең. |
| Ул | а́л + мый, | эшлә́ + ми. |
| Без | а́л + мый + быз, | эшлә́ + ми + без. |
| Сез | а́л + мый + сыз, | эшлә́ + ми + сез. |
| Алар | а́л + мый + лар, | эшлә́ + ми + ләр. |

**2.** Скажи о том, что:

не слушаешь, не любишь, не идёшь, не говоришь, не поздравляешь, не читаешь, не работаешь.

**3.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Без дәрестә́ я́змыйбыз, лә́кин ... .
2) Син китáп укы́мыйсың, чө́нки ... .

**4.** Җөмләләрне үрнәк буенча үзгәрт (измени).

Ү р н ә к: Айрáт китапханәгә́ бара́. – Айрáт китапханәгә́ бáрмый.

1) Айрáт китапханәчедә́н шигы́рь китабы́ соры́й.
2) Китапханәче́ Айраткá шигы́рь китабы́ бирә́.
3) Айраткá шигырьлә́р ошы́й.

**5.** Җөмләләрне дәвам ит.

1) Айрáт китапханәгә́ бáрмый, чө́нки ... .
2) Дусты́м китáп укы́мый, чө́нки ... .
3) Мин телеви́зор карáмыйм, лә́кин ... .

**6.** Диалогка төшеп калган (пропущенные) репликаларны яз. Дустың белән сөйләш.

1) – ... ?
– Юк, китапханәгә́ бáрмыйм.
– Телеви́зор кары́йсыңмы?
– Юк, ... .
– ... ?
– Әнигә́ булышáм.



2) – Ко́ля, ә́йдә китапханәгә́ бара́быз.
– ... .
– Ни́ өчен ба́рмыйсың?
– ... .

3) – Сезнéң өйдә́ ни́нди китапла́р бар?
– ... .
– Сезнéң өйдә́ кем кита́п укы́й?
– ... .
– Син быéл ни́чә кита́п укыды́ң?
– ... .
– Китапханә́ ка́йда урнашка́н?
– ... .

**7. Исеңдә калдыр!**

**турында́** – о, об, про
кыш турында́, дуслы́к турында́

**8.** Рассмотри рисунки и скажи, о чём книги.







**9.** Сообщи другу о том, что:

– ты не идёшь сегодня в библиотеку, потому что к вам придут гости;
– ты берёшь книгу о собаках;
– ты читаешь книгу о собаках.

**10.** Диалогны укы, иптәшең белән сөйләш.

– Керергә́ рөхсә́тме, Алсу́ апа?
– Рәхи́м ит, Наи́л, уз.
– Сездә́ космона́втлар турында́ ките́п ба́рмы?
– Әйе́, бар.
– Би́регез әле.
– Ме́нә, ал.
– Рәхмә́т.



## 31–32 нче дәресләр

**1.** Дәвам ит.

Мин саны́йм.
Син саный... .
Ул саны́й.

Без саный... .
Сез саный... .
Ала́р саный... .

**2. Исеңдә калдыр!**



| | |
|---|---|
| 10 – ун | 50 – илле́ |
| 20 – егерме́ | 60 – алтмы́ш |
| 30 – уты́з | 70 – җитме́ш |
| 40 – кыры́к | 80 – сиксә́н |
| 90 – тукса́н | |

**3.** Саннарны дөрес әйтергә өйрән.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 |

**4.** Үрнәк буенча дәвам ит.

| | | |
|---|---|---|
| 31 – утыз бе́р | 34 – ... | 37 – ... |
| 32 – ... | 35 – ... | 38 – ... |
| 33 – ... | 36 – ... | 39 – ... |

**5. Исеңдә калдыр!**

**пять тетрадей** – биш дәфтә́р
**три девочки** – өч кыз

**6.** Выбери правильный перевод словосочетания **восемь тетрадей:** а) сиге́з дәфтә́р; ә) сигезенче́ дәфтә́р.

**7.** Сөмбелә кайда ялгышты (ошиблась)?

**Сөмбелә́**

Дә́ү инде безне́ң Сөмбелә́,
Бишкә́ кадәр саны́й белә́:
– Бер,
И́ке,
Өч,
Дүрт,
Биш!
Ә́нә дөре́с саны́й ич!
– Я́ле, унга́ кадәр са́на! –
Дигә́н иде́к беркө́н аңа́.
Бола́й санап китте́ ул:
– А́лты,
Си́гез,
Җи́де,
Ун.

Әхмә́т Исха́к



**8.** **Исеңә төшер!**

| | |
|---|---|
| **Ни́чә?** – Сколько? | **Ни́чәнче?** – Который? |

**9.** Саннарны дәвам ит.

11 – унберенче́ 13 – ... 15 – ... 17 – ... 19 – ...
12 – ... 14 – ... 16 – ... 18 – ... 20 – ...

**10.** Кем ничәнче партада утыра?



Дами́р О́ля Серёжа Айгө́л Мара́т Искәндә́р

**11.** Шигырьне укы.

**Бер атнада́ ни́чә көн?**

Бер атнада́ ни́чә көн?
Бер атнада́ җиде́ көн.
Җиде́ төрле́ исеме́ –
Җидесе́н дә ятта́н бел:
Дүшә́мбе, сишә́мбе,
Чәршә́мбе,
Пәнҗешә́мбе, җомга́,
Шимбә́, якшә́мбе.




Гөлша́т Зәйна́шева

**җидесе́н дә** – все семь
**ятта́н бел** – знай наизусть

**12.** Назови дни недели в правильной последовательности.




## 33–34 нче дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Поздравь учительницу с праздником 1 сентября.

**2.** Атнаның җиде көнен әйт. Дүшәмбегә, сишәмбегә дәресләр расписаниесен яз.

**3.** К тебе приехал друг. Ты знакомишь его со школой. Как скажешь о том, что:

– это ваша школа;
– ты учишься в третьем классе;
– ты учишься хорошо (плохо, средне)?

**4.** Перед новым учебным годом ты пересмотрел свои учебные принадлежности. Оказывается, у тебя нет ручки (тетради, дневника). Как скажешь об этом маме?

**5.** Ты покупаешь тетради. Продавщица предлагает тетради в клетку, а тебе нужны тетради в линейку. Как ты об этом скажешь?

**6.** Сораугa җавап бир.

**Бу китапханә́ме?**










**7.** Переведи на татарский язык.

1) Я хожу в библиотеку, потому что много читаю.
2) Я пошёл в библиотеку, но она не работает.

**8.** Составь предложения со словами **янында́, лә́кин, чө́нки, турында́.**

**9.** Цифры потеряли свои обозначения, найди их.

10 –
20 –
30 –
40 –
50 –
60 –
70 –
80 –
90 –
100 –

алтмыш

туксан

ун

илле

егерме

сиксән

житмеш

утыз

йөз

кырык



**10.** Спроси у друга:

– приготовил ли он домашнее задание;
– что им задали на дом;
– какие оценки он получил сегодня;
– какие уроки ему нравятся.

# КӨНДӘЛЕК РЕЖИМ

## 35–36 нчы дәресләр

**1.** **Исеңдә калдыр!**



**Сәга́ть ни́чә?** – Который час?
**Сәга́ть ике́.** – Два часа.
**Сәга́ть ни́чәдә?** – Во сколько часов?
**Сәга́ть өчтә́.** – В три часа.

**2.** Сәгать ничә?



**3.** Найди в предложениях слова, отвечающие на вопрос **нишли?**

1) Гали́ йокыда́н тора́, заря́дка ясы́й, иртәнге́ ашны́ ашы́й. 2) Гали́ мәктәпкә́ китә́. 3) Гали́ мәктәптә́н кайта́. 4) Гали́ дәре́с әзерли́. 5) Гали́ я́л итә. 6) Гали́ йоклы́й.

**4.** Измени глаголы из упражнения №3 по образцу и запиши их.

| Үрнәк: **Ни́шли?** | **Ни́шләде?** |
|---|---|
| тора́ | торды́ |

**5.** Рәсемгә кара. Гали турында сөйлә.



**6.** Рассмотри рисунок упражнения №5 и спроси у Гали, когда он выполняет эти действия.

Ү р н ә к: Гали́, син ка́йчан йокыда́н тора́сың?

**7.** Дәвам ит.



а) Мин йокыда́н тора́м.
Син йокыда́н тора́сың.
Ул йокыда́н тора́.



ә) Мин заря́дка ясы́йм.
Син ... .
Ул ... .

# 37–38 нче дәресләр

**1.** Слова и словосочетания заблудились. Помоги им найти свой домик.

Йокыда́н торды́м, сикерде́м, дәре́с әзерләде́ң, ашады́м, йокыда́н торды́ң, чәй эчте́м, өйгә́ кайтты́ң, кино́ карады́м.







**2.** Измени слова по образцу.

Ү р н ә к: Мин сикерде́м, җырлады́м.
Син сикерде́ң, җырлады́ң.
Ул сикерде́, җырлады́.

С ү з л ә р: торды́, эчте́, ясады́, әзерләде́.

**3.** Дополни диалог и поговори с соседом по парте.

– Син сәга́ть ни́чәдә торды́ң?
– ... .
– Син сәга́ть ни́чәдә ашады́ң?
– ... .
– Син сәга́ть ни́чәдә мәктәпкә́ китте́ң?
– ... .
– Сәга́ть ни́чәдә мәктәптә́н кайтты́ң?
– ... .
– Сәга́ть ни́чәдә уйнады́ң?
– ... .

– Сәгáть ни́чәдә дәрéс әзерләдéң?
– … .
– Сәгáть ни́чәдә телеви́зор карадыќң?
– … .
– Сәгáть ни́чәдә йокларгá яттыќң?
– … .

**4.** Продолжи по образцу.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 – бер | 2 – … | 3 – … | 3 – … | 2 – … |
| 11 – унбéр | 22 – … | 12 – …. | 13 – … | 21 – … |

**5.** Как ответит Марат на вопросы?

– Марáт, син бүгéн сәгáть ни́чәдә йокыдáн тордыќң?
– … .
– Марáт, син бүгéн сәгáть ни́чәдә футбóл уйнадыќң?
– … .
– Марáт, син бүгéн сәгáть ни́чәдә кибеткә́ бардыќң?
– … .

**6. Исеңдә калдыр!**



**иртә́н** – утром
**иртәнгé аш** [иртәңгә̆́ а°ш] – завтрак

**көндéз** – днём
**көндезгé аш** [көндөзгө́ а°ш] – обед

**кич** – вечером
**кичкé аш** [кичкә̆́ а°ш] – ужин

**7.** Составь свой режим дня и расскажи другу.

1) Сәгáть ... йокыдáн торáм, иртәнгé аш ашы́йм.
2) Сәгáть ... мәктәптә́ укы́йм.
3) Сәгáть ... көндезгé аш ашы́йм.
4) Сәгáть ... я́л итәм.
5) Сәгáть ... дәрéс әзерли́м.
6) Сәгáть ... кичкé аш ашы́йм.
7) Сәгáть ... йоклы́йм.

**8.** Задайте друг другу вопросы по содержанию упражнения №7.



## 39–40 нчы дәресләр

**1.** Диалогны укы. Дустың белән сөйләш.

– Марáт, син кáйчан йокыдáн торáсың?
– Сәгáть жидедә́. Ә син?
– Ми́н дә жидедә́ торáм.
– Иртә́н син ни́шлисең?
– Юынáм, зарядка ясы́йм, чәй эчә́м. Аннáн соң (потом) мәктәпкә́ китә́м.
– Син ни́чәнче смéнада укы́йсың?
– Беренчé смéнада укы́йм, ә син?
– Ми́н дә беренчé смéнада.
– Мәктәптә́н сәгáть ни́чәдә кайтáсың?
– Сәгáть бердә́.

**2.** Расскажите друг другу о своём режиме дня.

**3.** Бу сүзләрне дөрес укыйсыңмы?

Сәгать [сәғә́т], даң-даң [да°ң да°ң], таң [та°ң], калган [ка°лға́н], Марат [ма°ра́т], харап [ха°ра́п], соңга калган [сŏңға́ қа°лға́н], карап йөр [қа°ра́п йөр].

**4.** Шигырьне укы.

**Сәга́ть**



Сәга́ть суга́: «Даң-даң!..»
Хәбә́р итә́ таңна́н:
Мәктәпкә́ барырга́
Унби́ш мину́т калга́н.
Сәга́ть йөри́: «Келт-келт!..
Тиз мәктәпкә́ кит, кит!..»
Мара́т аңа́ дәшә́:
«Ту́кта, мине́ көт, көт!»
Сәга́ть жырлы́й: «Диң-диң!..
Мин бит тукты́й бе́лмим.
Монна́н ары́, диң, диң!
Миңа́ кара́п йөр син!..»

Муса́ Җәли́л

**5.** Найди в стихотворении предложения, в которых говорится:

– о том, что Марат опоздал;
– о чём просит Марат у часов;
– о чём поют часы.

**6.** Выучи 4 понравившиеся строки стихотворения.

## 41 нче дәрес

**Проверь себя!**

1. Расскажи о своём режиме дня.

2. Спиши, вставляя пропущенные буквы.

1) Мин сәга́ть сигездә́ мәктәп... барды... . 2) Аза́т мәктәп... өйгә́ сәга́ть бердә́ кайта́. 3) Бәйрә́м сәга́ть унбердә́ башланды...? 4) Син урам... чыктың...?




3. Помоги Шурале назвать числа по порядку.

4. Как изменятся выделенные слова, если действия уже произошли?

Айда́р иртә́н **тора́**, заря́дка **ясы́й**, салкы́н су́ белән **юына́**. Анна́н соң чәй **эчә́** һәм мәктәпкә́ **китә́**.

5. Спроси у друга, во сколько часов он встал, пришёл в школу, вернулся из школы домой.

# АШХАНӘДӘ





## 42–44 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



**ашханә́** – столовая
**кәбестә́ ашы́** – щи
**ботка́** – каша
**токмачлы́ аш** – суп с лапшой
**пешекче́** – повар
**кесә́л** – кисель
**пешерә́** – варит

2. Бу сүзләрне дөрес укыдыңмы?

Ашханә [а°шхәнә́], пешекче [пә̆шә̆кчә̆́], токмачлы [тоқмачлы́], пешер [пә̆́шә̆р], төрле [төрлә́], ботка [бо̆тқа́], кәбестә [кәбә̆стә́].

3. Нокталар урынына тиешле кушымчаларны һәм сүзләрне куй.

1) Мин (ка́я?) ашханә... бара́м. 2) Мин (ка́йда?) ашханә... ашы́йм. 3) Мин (ка́йдан?) ашханә... чыга́м.

**4. Исеңә төшер!**

**иртәнге аш** [иртәңгә́ а°ш] – завтрак
**көндезге аш** [көндөзгә́ а°ш] – обед
**кичке аш** [кичкә́ а°ш] – ужин

**5.** Укы.

**Ашханәдә́**

Безне́ң мәктәптә́ ашханә́ бар. Пешекче́ апала́р тәмле́ ашла́р пешерә́ләр. Без көндезге́ ашны́ ашханәдә́ ашы́йбыз. Безгә́ ашханә́ ошы́й.

Меню́ төрле́-төрле́ була́. Безгә́ кәбестә́ ашы́ да, токмачлы́ аш та пешерә́ләр.

Ә боткала́р котле́т белән тәмле́ була́. Анна́н соң без чәй, компо́т, кесә́л эчә́без. Без пешекче́ апаларга́ рәхмә́т әйтә́без.



**6.** Җөмләләрне «Ашханәдә» тексты тәртибендә (по содержанию текста) урнаштыр.

1) Ә дөге́, карабода́й, солы́ боткалары́ котле́т белән тәмле́ була́. 2) Безне́ң мәктәптә́ ашханә́ бар. 3) Без көндезге́ ашны́ ашханәдә́ ашы́йбыз. 4) Безгә́ кәбестә́ ашы́ да, токмачлы́ а́ш та пешерә́ләр. 5) Без пешекче́ апаларга́ рәхмә́т әйтә́без.

**7.** Җөмләләрне киңәйтеп (распространив) яз.

Ү р н ә к: Ашханәдә́ ашы́йм.
Мин ашханәдә́ ашы́йм.
Мин бүге́н ашханәдә́ ашы́йм.
Мин бүге́н ашханәдә́ ботка́ ашы́йм.

Җ ө м л ә л ә р: Пешекче́ пешерә́. Без рәхмә́т әйтә́без.

**8.** Дополни диалоги. Поговори с соседом по парте.

а) – Сезне́ң мәктәптә́ ашханә́ ба́рмы?
– ... .
– ... ?
– Әйе́, мин ашханәдә́ көндезге́ ашны́ ашы́йм.
– Син нә́рсә ярата́сың?
– ... .
– Ми́н дә ботка́ ярата́м.





ә) – Ә́йдә ашханәгә́ бара́быз.
– ... .
– Ни́гә ба́рмыйсың?
– Мин ашады́м инде.

**9.** Спроси у друга:

– любит ли он каши;
– вкусно ли варят в столовой суп;
– нравится ли ему в столовой;
– пьёт ли он утром чай;
– ест ли он днём суп.

**10.** Бу ашамлыкларны пешекчеләрдән сора.




**11.** «Ашханәдә» текстын сөйләргә өйрән.

## 45–46 нчы дәресләр

**1.** Ә син бу ризык исемнәрен беләсеңме?



**2.** Рассмотри рисунки упражнения №1:

а) узнай у друга:
- любит ли он эти блюда;
- предложи ему эти блюда;
- нужны ли ему эти блюда;

б) спроси у повара:
- есть ли эти блюда;
- сколько они стоят.



**3.** Кайсы ризык татлы, кайсы ризык итле? Таблицага яз.

| Татлы́ ризыклáр | Итлé ризыклáр |
|---|---|
| ... | ... |

Р и з ы к л а р: ко́ш теле, бәле́ш, өчпочма́к, гөбәдия́, коймá́к, пилмә́н, алма́ пирогы́, чәкчә́к, токмачлы́ аш.

**4.** Җөмләләр төзе.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Без | көнде́з | ? | кичке́ аш | | |
| | иртә́н | | көндезге́ аш | | ашы́йбыз. |
| | кич | | иртәнге́ аш | | |

**5.** Вставь в диалоги пропущенные реплики.

а) – ... ?
– Әйе́, мин ботка́ ашады́м.
– ... ?
– Дөге́ боткасы́.
– ... ?
– Би́к тәмле́.

ә) – Бүге́н сезгә́ кунакла́р килә́ме?
– ... .
– Нә́рсәләр пешерә́сез?
– ... .

**6.** Предложи другу:

– вместе пообедать;
– пойти вместе в столовую.

**7.** Диалогны дәвам итегез.

– Исә́нмесез! Керергә́ мөмки́нме?
– Ке́регез, у́зыгыз, өстә́л янына́ у́тырыгыз!
– Рәхмә́т. Ни́нди мату́р өстә́л!
– Ә́йдәгез, җилә́к-җимешлә́р а́шагыз.
– ... .

**8.** Допустим, к вам пришли гости. Ты их приглашаешь за стол, угощаешь фруктами. Если ты правильно решишь кроссворд, то отгадаешь, кто к вам придёт.



## 47–49 нчы дәресләр

**1.** Җөмләләр төзе.

Мин  куя́м.

**2.** Бу сүзләрне дөрес укы.

Кашык [қа°шы́қ], кул [қул], урын [уры́н], авыз [а°wы́з], урындык [урынды́қ], пычак [пыча́қ].

**3.** Допустим, ты сидишь с другом за столом. Узнай:

– есть ли у него ложка, вилка, тарелка;
– будет ли он есть салат;
– будет ли он пить чай, компот.

**4. Исеңә төшер!**

| | |
|---|---|
| **Ке́мне?** – Кого?<br>әбине́, бабайны́ | **Нә́рсәне?** – Что? Чего?<br>чәйне́, ашны́, кашыкны́ |

**5. Исеңдә калдыр!**



| | |
|---|---|
| **ю** – мой<br>**сөрт** – вытирай | **та́рат** – раздай<br>**куй** – положи |

**6.** Нокталар урынына кушымчаларны куеп, күнегүне күчереп яз.

1) О́ля, пычак... сөрт.
2) Пе́тя, кулың... ю.
3) Айда́р, урындыгың... өстә́л янына́ куй.
4) Алсу́, чәнечкеләр... , кашыклар... та́рат.

**7.** Азат нишли?



**8.** Используя содержание упражнения №6, поговорите друг с другом.

**9.** Шигырьне укы.




### Аш вакыты́

Тәлинкә́, кашыкла́р,
Чәнечке́, пычакла́р
Тарата́ дежу́рный –
Аш урыны́ әзерли́...
Эштә́ би́к оста́ ул,
Чиста́ ул, пөхтә́ ул.
Тәлинкә́, кашыкны́ң
Битләре́н сөртә́ ул.
Тәртипне́ белә́без:
Кул юы́п керә́без.
Әйбәтлә́п кенә без
Ашы́йбыз, эчә́без.
Бер сүз дә дә́шмибез,
Тү́кмибез, чә́чмибез.
«Апа́, би́к рәхмә́т!» – дип,
Урынна́н тора́быз,
Авызны́ чайкы́йбыз,
Кулларны́ юа́быз,
Ә урындыкларны́
Урынына́ куя́быз.

Бари́ Рәхмә́т

**чайкы́йбыз** – полощем
**дә́шмибез, эндә́шмибез** – не говорим, молчим
**тү́кмибез, чә́чмибез** – не проливаем, не высыпаем
**урынына́ куя́быз** – ставим на место

**10.** Нокталар урынына сүзләр куй, җөмләләрне укы.

1) Дежу́р укучы́ ... әзерли́. 2) Дежу́р укучы́ ..., ..., ... тарата́. 3) Без ... юа́быз. 4) Без апага́ ... әйтә́без, ... урынына́ куя́быз.

**11.** Таблицаны тутыр, сөйләргә өйрән.

| Әдәпле (воспитанный) кеше | Әдәпсез (невоспитанный) кеше |
|---|---|
| кулы́н юа | кулы́н ю́мый |
| ... | ... |

**12.** Попроси сестру:

– вытереть ложки;
– положить салфетки;
– помыть посуду;
– раздать тарелки, ложки.

**13.** Как скажешь, если действия упражнения №11 выполнил ты? Запиши в тетрадь.

**14.** Таблицаны тутыр.

| Глаголы | Вопросы |
|---|---|
| сөрттé ң | сөрттéңме? |
| юды́ң | ... |
| куйды́ң | ... |
| тараттыы́ң | ... |

**15.** Спроси у сестры:

– вытерла ли она ложки;
– помыла ли она посуду;
– положила ли она салфетки;
– раздала ли она ложки.

**16.** Допустим, ты дежурный по столовой. Расскажи, что ты делаешь.

**17.** Шигырьне сәнгатьле укырга өйрән.

## 50–51 нче дәресләр

**1. Исеңдә калдыр!**



| **Ка́я?** | **Ка́йда?** | **Ка́йдан?** |
|---|---|---|
| янына́ | янында́ | яныннáн |



**өстә́л янына́**
(к столу)



**өстә́л янында́**
(у, около стола)



**өстә́л яныннáн**
(от стола)

**2.** Поставь к выделенным словам вопросы, переведи предложения.

1) О́ля **өстә́л янына́** утырды́.
2) О́ля **өстә́л яныннáн** китте́.
3) О́ля **өстә́л янында́** уйны́й.

**3.** Нокталар урынына кушымчалар өстә.

1) Ләйсә́н (ка́я?) такта́ яны... чыкты́.
2) Ләйсә́н (ка́йда?) такта́ яны... тора́.
3) Ләйсә́н (ка́йдан?) такта́ яны... китте́.

**4.** Как скажешь о том, что Марат:

– играет около школы;
– идёт в школу;
– отошёл от доски?

**5.** Диалогларны сөйләшегез.



а) – Пе́тя, чәй эчә́сеңме?
– Әйе́, эчә́м.
– Ә́йдә өстә́л янына́ у́тыр.
– Рәхмә́т.

ә) – Әни́, өстәлдә́ ипи́ юк.
– Улы́м, ипи́ шкафта́, үзе́ң ал.
– Рәхмә́т, әни́, хә́зер ала́м.

б) – Улы́м, мә ипи́, тәлинкәгә́ куй.
– Ярый́, әни́, куя́м.

**6.** Ноктaлар урынына кушымчалар куеп, күчереп яз.

1) Кашы́к (ка́я?) идән... төште́.
2) (Ка́йда?) Тәлинкә... икмә́к бар.
3) Икмәкне́ (ка́йдан?) тәлинкә... алды́.

**7.** Как скажешь о том, что ложка упала на пол? Попроси сестрёнку:

– поднять ложку с пола;
– положить ложку на стол.

**8.** Попроси Гузель:

– положить хлеб на тарелку;
– разложить ложки, вилки;
– поставить вазу на стол.

**9.** 8 нче күнегүне язмача эшлә.

## 52–54 нче дәресләр

**1.** **Исеңдә калдыр!**



Если ты хочешь сказать, что начинаешь что-либо делать, то говоришь так:
**уйны́й башлады́м** – я начал играть,
**эшли́ башлады́м** – я начал работать.

**2.** Тәрҗемә ит.

Мин уйны́й башлады́м. Без уйны́й башлады́к.
Син уйны́й башлады́ң. Сез уйны́й башлады́гыз.
Ул уйны́й башлады́. Ала́р уйны́й башладыла́р.

**3.** Скажи о том, что ты начал есть суп, пить чай, пить кисель.

**4.** Спроси у друга, начал ли он есть суп, пить чай, пить кисель.

**5.** Бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзеп, дәфтәреңә яз.

1) Ул, башлады́, өчпочма́к, ашы́й.
2) Тәлинкәләрне́, юа́, дежу́р, укучы́, башлады́.

3) Ко́ля, өстә́л, килде́, янына́, һәм, кисә́, ипи́, башлады́.

**6.** Рәсемнәргә кара һәм җөмләләр төзе.





**7.** Бу сүзләрне дөрес укырга өйрән.

Балалар [ба°лала́р], ашханә [а°шхәнә́], башлады [ба°шлады́], янына [йа°ныjна́], ясады [йа°сады́], куйды [қуйды́].

**8.** Текстны укы.

**Икмә́к**

Балала́р ашханәгә́ килделә́р һәм өстә́л янына́ утырдыла́р. Пешекче́ апа́ тәлинкәгә́ икмә́к куйды́. Искәндә́р икмә́к белән уйны́й башлады́. Ул икмәкне́ чәнечке́ белән алды́ һәм вертолёт ясады́. Икмә́к идәнгә́ төште́. Бөте́н кеше́ Искәндәргә́ карады́. Мала́й ипине́ идәннә́н алды́ да яңада́н (снова) тәлинкәгә́ куйды́.

Ә́йтегез әле, балала́р, Искәндә́р ни́нди нача́р эш эшләде́?

Хәлә́ф Гарда́новтан

**9.** Дөрес тәрҗемәләрне тап, алар белән җөмләләр төзе.

| **к столу** | **с пола** | **снова** |
|---|---|---|
| 1) өстәлдә́ | 1) идәндә́ | 1) яңада́н |
| 2) өстә́л янына́ | 2) идәннә́н | 2) анна́н соң |

**10.** Җөмләләрне «Икмәк» тексты эчтәлеге тәртибе буенча урнаштыр.

1) Искәндә́р икмәкне́ чәнечке́ белән алды́. 2) Пешекче́ апа́ тәлинкәгә́ икмә́к куйды́. 3) Мала́й икмәкне́ идәннә́н алды́ да яңада́н тәлинкәгә́ куйды́. 4) Балала́р ашханәгә́ килделә́р һәм өстә́л янына́ утырдыла́р.

**11.** Ике раслауның (из двух утверждений) кайсысы дөрес?

1) Искәндә́р өстә́л янында́ икмә́к белән уйнады́.
Искәндә́р өстә́л янында́ икмә́к белән уйна́мады.

2) Мала́й икмәкне́ идәннә́н алды́.
Мала́й икмәкне́ идәнгә́ куйды́.

**12.** Җөмләләрне киңәйтеп яз.

1) Балала́р килделә́р.
2) Пешекче́ апа́ куйды́.
3) Икмә́к төште́.

**13.** Тәрҗемә ит.

1) Я подошёл к столу. 2) Я беру со стола хлеб. 3) Он положил хлеб на стол. 4) Хлеб упал на пол. 5) Подними хлеб с пола.

**14.** Искәндәргә бу сыйфатларның (из этих качеств) кайсысы туры килә?

Эшчә́н, тыры́ш, яхшы́ мала́й, нача́р мала́й, ярдәмче́л, әдәпле́, әдәпсе́з.

**15.** Какие советы дадут друзья Искандеру?

**16.** Текст эчтәлеген план буенча сөйлә.

1) Балала́р ка́я килделә́р?
2) Пешекче́ апа́ тәлинкәгә́ нә́рсә куйды́?
3) Искәндә́р икмә́к белән нә́рсә ясады́?
4) Икмә́к ни́шләде?
5) Искәндә́р ни́нди нача́р эш эшләде́?

## 55–57 нче дәресләр

**1.** Нәрсә ашыйбыз, нәрсә эчәбез? Таблицага яз.

| Эчәбез | Ашыйбыз |
|---|---|
| ... | ... |

А ш а м л ы к л а р: сөт, аш, шулпа́, ит, ботка́, чәй, пилмә́н, йомырка́, каты́к, компо́т, кыстыбы́й, гөбәдия́, коймá́к, каймá́к, пыла́у, сок, кесә́л.

**2.** Син ризык исемнәрен дөрес укыйсыңмы? Үзеңне тикшер.

Бавырсак [ба°wы̆рса́қ], өчпочмак [өчпŏчма́қ], кош теле [қŏ́штә̆лә̆], бәлеш [бәлә̆́ш], сумса [сумса́], кыстыбый [қы̆сты̆бы̆́й].

**3.** 1 нче күнегүдәге ашамлык исемнәре белән 5 сорау җөмлә төзе.

**4.** Диалогны дәвам ит.

– Бүге́н ашханәдә́ кем дежу́р?
– Мин.
– Син анда́ ни́шлисең?
– ... .

**5.** Шигырьне укы.

**Кунакла́р**



Без әзерли́без табы́н,
Китере́п бө́тен ягы́н.
Уртага́ куйдыќ чәчә́к,
Чәчә́к янына́ – чәкчә́к,
Бавырса́к һәм кө́ш теле.
Ризыкла́р төрле́-төрле́ –
Сумса́, бәле́ш, өчпочма́к,
Гөбәдия́ һәм коймаќ.
Һә́ркемгә чыга́р өле́ш,
Бар кыстыбы́й һәм бәле́ш.
– Җи́тешегез, кунакла́р!
Кыста́тмагыз, кунакла́р!
Өйгә́ кайты́п китәргә́
Ашы́кмагыз, кунакла́р.

Шәүкә́т Гали́ев

**6.** Иптәшеңнән сора: өстәлдә нинди ризыклар бар, нинди ризыклар юк?

**7.** Ошаса, шигырьне ятла.

**8.** Диалогка төшеп калган җөмләләрне өстә, дустың белән сөйләш.

– Бүге́н сезгә́ кунакла́р килә́ме?
– … .
– Нә́рсәләр пешерә́сез?
– … .

**9.** Используя содержание стихотворения «Кунаклар», напиши, как ты накрываешь стол.

## 58–59 нчы дәресләр

### Проверь себя!

**1.** Татар халык ашлары исемнәрен ата (назови). Син аларның кайсыларын (которые из них) яратасың?

**2.** Найди соответствующий перевод. Составь предложения.

| | |
|---|---|
| өстә́л өстендә́ | около стола |
| өстә́л астында́ | под столом |
| өстә́л янында́ | на столе |
| өстә́л артында́ | перед столом |
| өстә́л алдында́ | за столом |

**3.** Нокталар урынына кушымчалар куеп, күчереп яз.

1) Мин мәктәп… кайта… .
2) Иртәгә́ мин әние́м белән кибет… бара… .
3) Әти́ эш… со́ң кайт… .

**4.** Как ты скажешь, что:



– завтракаешь дома;
– обедаешь в школе;
– ужинаешь с семьёй?

**5.** Попроси себе:

– суп с лапшой;
– рисовую кашу;
– щи.



**6.** Спроси у друга:

– какие каши он любит;
– какой суп он любит;
